ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2014 елның 14 ноябре. Казан, № 10-34/кс

***2015 елда эчә торган суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләү турында***

"Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турындагы" 7.12.2011 ел № 416-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендәге тарифларны дәүләти көйләү турындагы" 13.05.2013 ел № 406 карарына, "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендәге гамәлдәге тарифларны үзгәртүнең мөмкин булган иң зур максималь индексларын 2015 елда Россия Федерациясе субъектлары буенча уртача билгеләү турындагы" 11.10.2014 ел № 228-э/4 боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында кагыйдәләргә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүче һәм су бүлүче оешмалар өчен эчә торган су һәм су бүлүнең календарь буенча бүленгән тарифларын әлеге карарның кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 декабреннән 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүче һәм су бүлүче, әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән оешмалар ирекле алынмалы мәгълүмәтне су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17.01.2013 ел № 6 карары белән расланган мәгълүмәт ачу стандартларына ярашлы рәвештә чираттагы көйләү дәверенә тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән соң 30 календарь көннән дә соңармыйча ачарга тиеш.

4. Әлеге карар аны рәсми игълан итү көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 14.11.2014 № 10-34/кс
карарына кушымта

# Салкын су белән тәэмин итүче һәм су бүлүче оешмалар өчен эчә торган су һәм су бүлүнең 2015 елга календарь буенча бүленгән тарифлары

| Т. № | Муниципаль берәмлек, салкын су бирүче һәм су бүлүче оешма исеме | Эчә торган су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су бүлү тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2015-30.06.2015 | 01.07.2015-31.12.2015 | 01.01.2015-30.06.2015 | 01.07.2015-31.12.2015 |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | | |
| 1 | «ЖКПСП «ИНФОСЕРВИС» ҖЧҖ* | | | | |
| 1.1 | Кузайкино авыл җирлеге кулланучылары | 19,44 | 19,91 | 11,87 | 12,75 |
| 1.2 | Ерсубайкино авыл җирлеге кулланучылары | 10,64 | 11,48 | | |
| 2 | «ЖКХ-Шешма» ҖЧҖ* | 12,41 | 13,27 | | |
| 3 | «ЖКХ-Суркино» ҖЧҖ* | 11,53 | 12,31 | | |
| 4 | «ЖКХ-Родник» ҖЧҖ* | 16,85 | 17,45 | | |
| 5 | «ЖКХ-Яңа Нәдер» ҖЧҖ* | 14,15 | 14,41 | | |
| 6 | «ЖКХ-Васильевка» ҖЧҖ* | 11,67 | 12,43 | | |
| 7 | «Айзат» ҖЧҖ* | | | | |
| 7.1 | Сәрән авыл җирлеге кулланучылары | 13,12 | 14,04 | | |
| 7.2 | Клементейкино авыл җирлеге кулланучылары | 16,63 | 16,63 | | |
| 7.3 | Баграж-Никольский авыл җирлеге кулланучылары | 9,25 | 9,71 | | |
| 7.4 | Борискино авыл җирлеге кулланучылары | 13,39 | 14,32 | | |
| 7.5 | Түбән Абдул авыл җирлеге кулланучылары | 15,17 | 15,84 | | |
| 7.6 | Елховка авыл җирлеге кулланучылары | 15,28 | 16,02 | | |
| 8 | «ЖКХ-Абдрахман» ҖЧҖ* | 17,20 | 17,81 | | |
| 9 | «ЖКХ-Тайсуган» ҖЧҖ* | 13,63 | 14,64 | | |
| 10 | «ЖКХ-Сөләй» ҖЧҖ* | 15,60 | 16,07 | | |
| 11 | «ЖКХ «Миңлебай» ҖЧҖ* | 14,85 | 15,30 | | |
| 12 | Хосусый эшмәкәр «Хәсәнов Ф.Ф.»* | 15,41 | 16,40 | | |
| 13 | «ЖКХ-Зверь» ҖЧҖ* | 22,69 | 23,88 | 17,00 | 17,52 |
| 14 | «ЖКХ-Аппак» ҖЧҖ* | 11,99 | 12,93 | | |
| 15 | «ЖКХ Яңа Кәшер» ҖЧҖ* | 12,84 | 13,74 | | |
| 16 | «ШАНС» ҖЧҖ* | 21,66 | 21,66 | | |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге